РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

САТЫШЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Сатышево, улЛенина , 17Б
тел. (84362) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатыш авылы, Ленин урам,17Б йорт
тел. (84362) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
20.10.2025

КАРАР
№90

Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитетының 21.10.2024 №36 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2025 ел, №304-ФЗ Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 21.10.2024 ел, №36 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре федераль башкарма хакимият органнарының, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнарының, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнарының, шулай ук җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең ризалыгын алу күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләп ителми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин